ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.11.2022 г. Заинск № 566

**2023 елга «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслары белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларын раслау турында**

«Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын махсус билгеләнгән автобусларда мәктәпкә йөртүне оештыруны финанслау нормативларын исәпләү буенча методик рекомендацияләрне раслау турында» 2010 елның 05 июлендәге 545 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 2 пункты нигезендә һәм Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Түбәндәге кушымталарны расларга:

2023 елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын махсус билгеләнгән автобусларда мәктәпкә йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары (1 кушымта);

Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын махсус билгеләнгән автобусларда мәктәпкә йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә (2 кушымта).

2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган махсус билгеләнгән автобусларда укучыларны мәктәпкә йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларына туры китереп, гомуми белем бирү оешмаларын финанслауны.

3. Карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми

порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы** **Р.М.Архипова**

Э.Р. Сәфәргалиев
3-27-42

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның «09» 11
566 номерлы карарына
1 кушымта

2023 елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделенең исеме | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, бер елга сумда | автотранспорт чарасының бер километр юл үтүенә ставка, сумда |
| КАВЗ | 613418 | 20,86 |
| ПАЗ | 613675 | 21,02 |
| ГАЗ «Газель» | 593227 | 13,56 |
| УАЗ | 592774 | 11,87 |
| FIAT | 596122 | 9,98 |
| Peugeot Boxer | 601272 | 9,61 |
| Ford Transit | 601529 | 13,74 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 615632 | 18,67 |

**Эшләр идарәчесе** **Т.А. Лоптова**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның «09» 11
566 номерлы карарына
2 кушымта

Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда мәктәпкә йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында
нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын мәктәпкә йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең (алга таба - муниципаль хезмәт) бәясен исәпләү механизмын билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чараларының саны һәм хисап чорында автотранспорт чараларының фактта үткән юлы нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары ел саен «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының фактта үткән юлы турында мәгълүмат Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча автотранспорт чарасы маршрутының расланган паспорты кысаларында башкарылган эш хисап елында автотранспорт чарасының фактта үткән юлы буларак кабул ителә.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1. Стоимость предоставления муниципальной услуги *i*-го муниципального образования рассчитывается по следующей формуле: i-муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\ m} \times NF_{km_m} + NF_{as\ m} \times M_m),$$

биредә:

$S_i$ – муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\,m}$ - m модельле автотранспорт чараларының фактта үткән юлы, километрда;

$NF_{km_m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын махсус билгеләнгән автобусларда мәктәпкә йөртүне оештыру нормативы ставкасы, бер километрга, сумда;

$NF_{as\,m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын махсус билгеләнгән автобусларда мәктәпкә йөртүне оештыру нормативы ставкасы, бер автотранспорт чарасына, сумда;

$M_m$ - m модельле автотранспорт чаралары саны, берәмлек;

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделенең номеры;

$k$ - муниципаль берәмлектә файдаланыла торган автобус модельләре саны.

**Эшләр идарәчесе** **Т.А. Лоптова**